**МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.01.2017 № 21-72-4

Казан ш.

Дәүләт эчке финанс контрольлеген
хәл итү стандартларын
раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 269.2 статьясындагы 3 пункты, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 101 статьясындагы 2 пункты нигезендә, боерык бирәм:

1. Дәүләт эчке финанс контрольлеген хәл итү стандартларын (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры – Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары М.Д.Фәйзрахмановка йөкләргә.

Министр Р.Р. Гайзатуллин

Татарстан Республикасы

Финанс министрлыгының

_______2017 ел, № ____

боерыгы белән расланды

# Дәүләт эчке финанс контрольлеген хәл итү стандартлары

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Дәүләт эчке финанс контрольлеген хәл итүнең бу Стандартлары (алга таба - Стандартлар) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 269.2 статьясындагы 3 пункты, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 101 статьясындагы 2 пункты нигезендә эшләнде.

1.2. Стандартлар, Россия Федерациясе бюджет законы нигезендә, финанс-бюджет өлкәсендә дәүләт эчке финанс контрольлеген хәл итү буенча төп принципларны һәм бердәм таләпләрне билгеләүче норматив документ булып тора.

1.3. Стандартларның максаты булып контрольлек чаралары этаплары характеристикаларын, аларны үткәрү кагыйдәләрен һәм процедураларын билгеләү тора.

1.4. Стандартның бурычлары булып контрольлек чарасы этапларын оештыру тәртибен, контрольлек чаралары этапларын үткәрүнең гомуми кагыйдәләрен һәм процедураларын билгеләү, шулай ук контрольлек чарасы нәтиҗәләрен тормышка ашыру механизмнарын, үткәрелгән контрольлек чарасы нәтиҗәләрен тормышка ашыруга контрольлек итү кагыйдәләрен билгеләү тора.

1.5. Контрольлек чарасы – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының (алга таба – Министрлык) дәүләт эчке финанс контрольлеге буенча вәкаләтләрен тормышка ашыруны тәэмин итү өчен контрольлек эшчәнлеген хәл кылуны оештыру формасы.

Контрольлек чарасы төшенчәсе түбәндәге таләпләргә җавап биргән чараны аңлата:

дәүләт эчке финанс контрольлеген хәл итү буенча Министрлыкның эш планы яки Татарстан Республикасы финанс министры (алга таба – Министр) карары нигезендә хәл ителә;

контрольлек чарасын үткәрү турында карар Министр боерыгы нигезендә рәсмиләштерелә;

аны үткәрү программасы нигезендә уздырыла (бердән күбрәк мәсьәлә тикшерелгән очракта);

контрольлек чарасы нәтиҗәләре буенча акт (бәяләмә) рәсмиләштерелә, ул Министрга яки аның кушуы буенча Министрның беренче урынбасарына, Министр урынбасарларына тапшырыла.

Контрольлек чарасын үткәрү контрольлек чарасы максатлары һәм мәсьәләләре нигезендә дәлилләр булдыру өчен кирәкле булган контрольлек гамәлләрен хәл кылудан, факттагы мәгълүматларны җыю һәм анализлаудан гыйбарәт.

1.6. Контрольлек объектлары булып тора:

Татарстан Республикасы бюджет средстволарын баш бүлүчеләр (бүлүчеләр, алучылар), Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары (администраторлар), Татарстан Республикасы бюджет дефицитын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлар);

финанс органнары (баш бүлүчеләр (бүлүчеләр) һәм үзләренә бюджетара трансфертлар бирелгән бюджет средстволарын алучылар), Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар, бюджет кредитлары бирүнең максатларын, тәртибен һәм шартларын үтәү ягыннан, шулай ук аларның дәүләт (муниципаль) программаларында күздә тотылган максатчан күрсәткечләргә һәм индикаторларга туры килердәй әлеге средстволардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү ягыннан;

гамәлдәге закон нигезендә, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре;

гамәлдәге закон нигезендә, дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләре;

устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашындагы хуҗалык оешмалары һәм ширкәтләр, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый оешмалар һәм ширкәтләрнең өлеше (кертеме) булган коммерция

оешмалары;

юридик затлар (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән, дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашындагы хуҗалык оешмалары һәм ширкәтләрдән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый оешмалар һәм ширкәтләрнең өлеше (кертеме) булган коммерция оешмаларыннан тыш), хосусый эшмәкәрләр, физик затлар, Татарстан Республикасы бюджетыннан средстволар бирү турында килешүләр (шартнамәләр), дәүләт контрактлары шартларын үтәү, Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре белән тәэмин ителгән кредитлар һәм займнар бирү тәртибен һәм шартларын үтәү, бюджет средстволарын мондый юридик затларның кыйммәтле кәгазьләренә урнаштыру максатларын, тәртибен һәм шартларын үтәү ягыннан:

Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды идарәсе органнары:

мәҗбүри медицина иминиятләштерүен финанс ягыннан тәэмин итү турында килешүләр буенча Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетыннан средстволар алучы юридик затлар;

бюджет средстволары белән аерым операцияләрне хәл итүче кредит оешмалары,Татарстан Республикасы бюджетыннан средстволар бирү турында килешүләр (шартнамәләр) шартларын үтәү ягыннан

гамәлләре, “Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында” 5 апрель, 2013 ел, № 44-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуга юнәлдерелгән заказчылар, контракт хезмәтләре, контракт идарәчеләре, сатып алуларны хәл кылу буенча комиссияләр һәм аларның әгъзалары, вәкаләтле органнар, вәкаләтле учреждениеләр, махсус оешмалар.

1.7. Контрольлек чарасын үткәрү өчен контрольлек чарасы максатлары һәм мәсьәләләре нигезендә дәлилләр булдыруда кулланылачак факттагы мәгълүматлар җыю ысулларыннан берсен: тикшерү, ревизия, тикшеренү арасыннан берсен сайлап алырга кирәк. Теге яки бу ысулны сайлап алу контрольлек чарасы максатларына һәм бурычларына бәйле.

2. Контрольлек чараларын планлаштыру

2.1. Контрольлек чараларын планлаштыру, “Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының финанс-бюджет өлкәсендә контрольлек вәкаләтләрен хәл кылу тәртибен раслау турында” (алга таба - Тәртип) 07.02.2014 ел, № 67 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының финанс-бюджет өлкәсендә контрольлек вәкаләтләрен хәл кылу тәртибенә туры китереп, һәр календарь елы өчен хәл ителә.

2.2. Контрольлек чараларын планлаштыру түбәндәге критерийләрдән чыгып хәл ителә:

үзләренә карата финанс контрольлеген үткәрү күздә тотылган контрольлек объектларында хәл ителергә тиешле контрольлек чараларының һәм (яки) бюджет чыгымнары юнәлешләре һәм күләмнәренең әһәмияте;

бюджет средстволарының баш администраторлары тарафыннан эчке финанс контрольлегенең һәм эчке финанс аудитының хәл ителүенә анализ ясау нәтиҗәсендә алынган, контрольлек объектына карата эчке финанс контрольлеге һәм аудиты торышын бәяләү:

дәүләт финанс контрольлеге органы тарафыннан үткәрелгән шундый ук контрольлек чарасыннан соң узган чор озынлыгы (әлеге чор 3 елдан артып киткән очракта әлеге критерий иң зур өстенлеккә ия була);

дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнарыннан, җирле хакимиятләрдән, Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторларыннан алынган, шулай ук сатып алулар өлкәсендәге бердәм мәгълүмат системасы мәгълүматларына ясалган анализ нәтиҗәләре буенча ачыкланган закон бозу билгеләренең булуы турында мәгълүмат.

Министрлыкның контрольлек чаралары планын булдыру, контрольлек чараларының кабатлануын булдырмау максатыннан, башка дәүләт органнары тарафыннан планлаштырыла (үткәрелә) торган шундый ук контрольлек чаралары турында мәгълүматлардан чыгып хәл ителә.

2.3. Планда чираттагы елда үткәрү өчен планлаштырыла торган контрольлек чаралары исемлеге билгеләнә, һәм бу планда түбәндәгеләр күрсәтелә торган

графалар булырга тиеш:

а) контрольлек чарасы атамасы;

б) контрольлек чарасы объекты;

в) контрольлек ысулы;

г) контрольлек чарасын үткәрү чоры;

д) үтәлеш өчен җаваплы структур подразделение.

2.4. Контрольлек чаралары планы Тәртип нигезендә раслана.

2.5. Һәрбер контрольлек чарасын планлаштыру, контрольлек объектын башлангыч төстә өйрәнүдән, контрольлек чарасы планын, программасын эшләү, контрольлек чарасы йомгаклары буенча акт төзүдән алып, контрольлек чарасы нәтиҗәләре турында хисап рәсмиләштерүгә һәм контрольлек чарасы материалларын тормышка ашыруга кадәр, контрольлек чарасының барлык этапларының бер-берсенә бәйлелеген тәэмин итү максатында хәл ителә.

3. Контрольлек чараларын оештыру һәм үткәрү

3.1. Контрольлек чарасын оештыру түбәндәге этаплардан тора, аларның һәркайсында билгеле бер бурычлар үтәлә:

әзерләнү этабы;

төп этап;

йомгаклау этабы.

3.2. Контрольлек чарасының башлангыч этабы контрольлек предметы һәм объектын башлангыч төстә өйрәнүдән, контрольлек чарасы максатларын һәм мәсьәләләрен, аны үткәрү ысулларын, тикшерү (ревизия) төркеме составын билгеләүдән гыйбарәт.

Әлеге этапның нәтиҗәсе булып контрольлек чарасы боерыгын һәм программасын әзерләү һәм раслау тора.

3.2.1. Контрольлек чарасын үткәрү турында карар Министр боерыгы белән рәсмиләштерелә, анда күрсәтелә:

контрольлек объекты атамасы;

булачак контрольлек чарасында тикшерелә торган чор;

контрольлек чарасы темасы:

контрольлек чарасын үткәрүгә нигез;

контрольлек чарасын үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар составы;

контрольлек чарасын үткәрү срогы;

контрольлек чарасын үткәрү барышында өйрәнергә тиешле төп мәсьәләләр исемлеге.

3.2.2. Контрольлек чараларын үткәрү ысуллары булып планлы һәм планнан тыш тикшерүләр тора:

тикшерүләр (билгеле бер чорда контрольлек объекты эшчәнлегенә карата аерым бер финанс һәм хуҗалык операцияләренең законлылыгын, бюджет (бухгалтерия) учеты һәм бюджет (бухгалтерия) хисабының дөреслеген документлар нигезендә һәм фактта өйрәнү буенча контрольлек гамәлләрен кылу);

ревизияләр (контрольлек объекты эшчәнлеген комплекслы тикшерү, анда хәл ителгән барлык финанс һәм хуҗалык операцияләренең законлылыгын, аларның бюджет (бухгалтерия) хисабында дөрес итеп чагылдырылуын документлар нигезендә һәм фактта өйрәнү буенча контрольлек гамәлләрен хәл кылудан гыйбарәт);

тикшеренүләр (контрольлек объекты эшчәнлегенең билгеле бер өлкәсе торышын анализлау һәм бәяләү).

3.2.3. Тикшерүләр түбәндәгечә бүленә:

Күчмә - контрольлек объектына карата тиешле контрольлек гамәлләре контрольлек объектының урнашу урыны һәм күчмә тикшерү актын рәсмиләштерү урыны буенча хәл ителә;

камераль - тиешле контрольлек чаралары Министрлыкның (аның структур подразделениеләре) урнашу урыны буенча үткәрелә, шул исәптән Министрлык запрослары буенча тапшырылган бюджет (бухгалтерия) хисабы, шулай ук кара-каршы тикшерүләр (встречная проверка) барышында һәм Министрлык тарафыннан файдаланыла торган мәгълүмати системалардагы мәгълүматларны анализлау нәтиҗәсендә алынган мәгълүматлар, документлар һәм материаллар нигезендә;

кара-каршы тикшерү – контрольлек объекты эшчәнлегенә бәйле булган фактларны билгеләү һәм (яки) раслау максатыннан чыгып, күчмә һәм (яки) камераль

тикшерүләр кысаларында тиешле контрольлек гамәлләрен хәл кылу.

тикшеренү – Министр боерыгы белән билгеләнә торган, контрольлек объекты эшчәнлеге өлкәсенең торышын анализлау һәм бәяләү, камераль һәм күчмә тикшерүләр (ревизияләр) кысаларында үткәрелә.

3.2.4. Контрольлек чарасын үткәрү срогы, тикшерү (ревизия) төркеменең персональ составы, Тәртип нигезендә, контрольлек чарасы темасыннан, алда торучы контрольлек гамәлләре күләменнән, контрольлек объектының финанс-хуҗалык эшчәнлеге үзенчәлекләреннән чыгып билгеләнә.

3.2.5.Контрольлек чарасын үткәрү турында боерыкка кушымта булып контрольлек чарасы программасы тора.

Контрольлек чарасы программасы түбәндәгеләрдән торырга тиеш:

тикшерү темасы;

контрольлек объекты атамасы;

тикшерү барышында өйрәнелергә тиешле мәсьәләләр исемлеге.

Бер генә мәсьәләне өйрәнү очрагында контрольлек чарасы программасы төзелми.

3.2.6. Тикшерү (ревизия) төркемендә катнашучылар (контрольлек чарасын үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи зат) контрольлек чарасын үткәрүгә әзерләнгәндә контрольлек чарасы программасын, контрольлек чарасы темасы буенча законнар һәм башка норматив-хокукый актларны, моңа кадәрге контрольлек чаралары материалларын өйрәнә.

3.3. Контрольлек чарасының төп этабы контрольлек гамәлләрен хәл кылудан, куелган максатларга һәм бурычларга ирешү өчен, шулай ук контрольлек чарасын үткәрү программасына кертелгән контрольлек чарасы мәсьәләләрен ачу өчен кирәкле булган факттагы мәгълүматларны җыю һәм анализлаудан гыйбарәт.

Әлеге этапны үткәрү нәтиҗәсе булып тикшеренү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштереп имзаланган тикшерүләр (ревизияләр) актлары, бәяләмәләр тора.

3.3.1. Контрольлек чарасын башлап җибәрү датасы булып аны үткәрүгә боерыкта күрсәтелгән дата санала.

3.3.2. Контрольлек чарасын тәмамлау датасы булып аны үткәргән Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан тикшерү (ревизия) актына,

тикшеренү нәтиҗәләре буенча бәяләмәгә имза салу датасы санала.

3.3.3. Контрольлек чарасы тикшерү (ревизия) төркемендә катнашучылар тарафыннан түбәндәгеләрне хәл кылу юлы белән үткәрелергә мөмкин:

контрольлек объектының гамәлгә кую, теркәү, план, бухгалтерия, хисап һәм башка документларын өйрәнү, анализлау һәм бәяләү;

бухгалтерия (бюджет) учетында һәм бухгалтерия (бюджет) хисабында хәл ителгән финанс һәм хуҗалык операцияләренең тулылыгын, шул исәптән учет регистрларындагы язуларны беренчел учет документлары, бухгалтерия (бюджет) хисабы күрсәткечләрен акча средстволарыннан һәм матди кыйммәтләрдән файдалануның нәтиҗәлелеге һәм рациональлелегенең аналитик учеты мәгълүматлары белән чагыштыру нигезендә, үз вакытында һәм дөрес чагылдырылуын тикшерү;

Татарстан Республикасы милкендәге акча средстволарының, кыйммәтле кәгазьләрнең һәм катгый хисап бланкларының фактта булуын, сакланылышын һәм дөрес файдаланылышын, исәп-хисапларның, җибәрелгән товарлар, башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр күләменең, чыгымнарны формалаштыру операцияләренең һәм финанс нәтиҗәләренең дөреслеген тикшерү;

Министрлык тарафыннан үткәрелгән моннан алдагы контрольлек чаралары нәтиҗәләре буенча закон бозуларны юкка чыгару, матди зыянны каплау, гаепле затларны җаваплылыкка тарту чараларының тормышка ашырылганлыгын тикшерү.

3.3.4. Контрольлек чарасы аны үткәрүгә боерыкта күрсәтелгән срокта башкарыла.

3.3.5.Контрольлек чарасы Тәртип нигезенедә туктатып торылырга мөмкин.

3.3.6. Контрольлек чаралары барышында контрольлек объекты эшчәнлеген документлар нигезендә һәм фактта өйрәнү буенча контрольлек гамәлләре үткәрелә.

Объект эшчәнлеген документлар нигезендә өйрәнү буенча контрольлек гамәлләре финанс, бухгалтерия, хисап документлары буенча хәл ителә, шулай ук контрольлек объектының вазыйфаи, матди яктан җаваплы затларының һәм башка затларының язмача аңлатмаларыннан, белешмәләре һәм мәгълүматларыннан һәм башка контрольлек гамәлләреннән чыгып, алардан алынган мәгълүматларны анализлау һәм бәяләү юлы белән хәл ителә.

Фактта өйрәнү буенча контрольлек гамәлләре карау, инвентарьләштерү, күзәтү, яңадан исәпләү, экспертиза ясау, контроль үлчәү һәм башка контрольлек гамәлләрен хәл кылу юлы белән үткәрелә.

3.4. Контрольлек чарасының йомгаклау этабында Министр тарафыннан түбәндәге карарлар кабул ителә:

тикшерү (ревизия) актын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча:

контрольлек объектына күрсәтмә һәм (яки) танытма җибәрү һәм (яки) бюджет мәҗбүриләве чараларын куллану турында уведомление җибәрү өчен нигезләрнең булуы турында;

күрсәтмә, танытма һәм бюджет мәҗбүриләве чараларын куллану турында нигезләрнең булмавы хакында;

планнан тыш күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү турында;

тикшеренү нәтиҗәләре буенча бәяләмәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча – күчмә тикшерү (ревизия) билгеләү (билгеләү өчен нигезләр булмау) турында.

3.4.1. Кара-каршы тикшерү нәтиҗәләре тикшерү (ревизия) материалы составында карала. Кара-каршы тикшерү нәтиҗәләре буенча кара-каршы тикшерү объектына күрсәтмәләр һәм танытмалар җибәрелми.

## 4. Контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү

4.1. Контрольлек чарасы нәтиҗәләре, Тәртип нигезендә, тикшерү (ревизия) акты һәм тикшеренү нәтиҗәләре бәяләмәсе нигезендә рәсмиләштерелә.

4.2. Тикшерү (ревизия) акты, тикшеренү нәтиҗәләре буенча бәяләмә тутырганда түбәндәге таләпләр үтәлергә тиеш:

контрольлек чарасы нәтиҗәләрен бәян итүдә объективлык, кыскалык һәм ачыклык;

ачыкланган закон бозулар һәм кимчелекләрнең эчтәлегенең төгәллеге;

бәян ителә торган материалның логик һәм хронологик эзлеклелеге;

контрольлек эшчәнлеген хәл итүче вазыйфаи затлар тарафыннан тикшерелгән тиешле документлар материаллары нигезендә генә, аларга тулы сылтамалар белән, фактагы мәгълүматларны бәян итү;

Актка (бәяләмә) тиешле документлар белән расланмаган төрле гөманлаулар

һәм мәгълүматлар, шулай ук хокук саклау (тикшерү) органнары материалларыннан мәгълүматлар кертергә ярамый.

Актта (бәяләмә) контрольлек объекты вазыйфаи һәм матди җаваплы затларының гамәлләренә мораль-этик бәя, шулай ук юридик терминнар кулланып характеристика бирергә (бу кадәресе хокук саклау органнарына йөкләнә) ярамый.

4.3. Тикшерү (ревизия) акты кереш һәм тасвирлама өлешләреннән тора.

4.3.1. Тикшерү (ревизия) актының кереш өлеше түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

тикшерү (ревизия) темасы;

тикшерү (ревизия) актын тутыру датасы һәм урыны;

тикшерү (ревизия) үткәрү турында боерык номеры һәм датасы;

тикшерү (ревизия) билгеләүгә нигез, шул исәптән планлы булу-булмавы, яки тиешле органның мөрәҗәгате, таләбе яки кушуы буенча үткәрелүе күрсәтелә;

ревизия төркеме җитәкчесенең һәм төркемдәге барлык әгъзаларның фамилияләре, инициаллары һәм вазыйфалары:

тикшерелә торган чор;

тикшерү (ревизия) үткәрү срогы;

контрольлек объекты турында мәгълүматлар:

тулы һәм кыскача атамасы; салым түләүченең идентификация номеры (ИНН), контрольлек объектының төп дәүләт теркәү номеры (ОГРН);

контрольлек объектының урнашу урыны;

контрольлек объектының гамәлгә куючылары (катнашучылары) турында мәгълүматлар;

эшчәнлекнең тиешле төрләрен алып баруга лицензияләр;

кредит оешмаларында барлык счетлары исемлеге һәм реквизитлары, депозит, шулай ук лицевой счетларны кертеп (тикшерелә торган чорда гамәлдә булган, әмма ревизия (тикшерү) вакытына ябылган счетларны кертеп);

тикшерелә торган чорда акча һәм исәп-хисап документларына имза салу хокукына ия булган затларның фамилияләре, инициаллары һәм вазыйфалары;

моңа кадәрге тикшерү (ревизия) үткәрү датасы;

ревизия төркеме җитәкчесе фикеренчә, контрольлек объектына тулы

характеристика бирү өчен кирәкле башка мәгълүматлар.

4.3.2. Тикшерү (ревизия) актының, тикшеренү нәтиҗәләре буенча бәяләмәнең тасвирлама өлеше контрольлек чарасының һәр мәсьәләсе буенча башкарылган эш һәм ачыкланган закон бозулар нәтиҗәләреннән торырга тиеш.

Тикшерү (ревизия) актында, тикшеренү нәтиҗәләре буенча бәяләмәдә контрольлек чарасын үткәрүдә ачыкланган һәр закон бозу очрагын тасвирлаганда күрсәтелергә тиеш: санга сугылмаган норматив-хокукый актлар нигезләмәләре; ачыкланган закон бозуның кайсы чорга керүе; закон бозуның нәрсәдән гыйбарәт булуы; закон бозуның документлар нигезендә расланган суммасы.

4.4. Контрольлек чарасы материаллары акттан һәм актка рәсмиләштерелгән кушымталарыннан тора, актта кушымталарына (документлар, документлар күчермәләре, җыелма белешмәләр, вазыйфаи һәм матди җаваплы затларның аңлатмалары һ.б.) сылтамалары булган.

Соралган аңлатмалар, белешмәләр, мәгълүматлар һәм документлар күчермәләрен тапшырудан баш тарту очрагында актта тиешенчә язып куела.

Бер үк төрле берничә документ мәгълүматларын бергә кушу нәтиҗәсендә алынган финанс бозуы расланганда, тиешле мәгълүматлар реестры тутырыла, бу реестр документларга (күчермәләре) кушып куела.

## 5. Контрольлек чаралары нәтиҗәләрен тормышка ашыру

5.1. Үткәрелгән контрольлек чаралары нәтиҗәләрен тормышка ашыру төшенчәсе контрольлек объектларына күрсәтмәләр һәм (яки) танытмалар җибәрүне, бюджет мәҗбүриләве чараларын кулланууны аңлата.

5.2. Танытма төшенчәсе Россия Федерациясе бюджет законын, бюджетка кагылышлы хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салучы башка норматив-хокукый актларны санга сукмау очраклары, Татарстан Республикасы бюджетыннан средстволар бирү турында килешүләр (шартнамәләр), дәүләт контрактлары шартларын, дәүләт гарантияләре белән тәэмин ителгән кредитлар һәм займнар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын, Татарстан Республикасы бюджет средстволарын контрольлек объектларының кыйммәтле кәгазьләренә урнаштыру максатларын, тәртибен һәм шартларын бозу турында карап тикшерү мәҗбүри булган

мәгълүматлардан, шулай ук мондый бозуларның сәбәпләрен һәм шартларын юкка чыгару буенча чаралар күрү турында карап тикшерү мәҗбүри булган таләптән, яки Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән средстволарны кире кайтару турында карап тикшерү мәҗбүри булган таләптән (бу документта билгеләнгән срокта яки, срогы күрсәтелмәсә, документны алганнан соң 30 календарь көне эчендә карап тикшерелергә тиешле) торган документны аңлата.

Министрлык танытмасында булырга тиеш:

контрольлек чарасы турында төп мәгълүматлар (аны үткәрүгә нигез, контрольлек чарасы атамасы, контрольлек объекты атамасы, шулай ук контрольлек чарасын үткәрү сроклары);

контрольлек чарасын үткәрү барышында ачыкланган закон бозулар,

закон бозулар суммасы (булганда). закон бозу датасы (чоры);

санга сугылмаган норматив-хокукый актлар нигезләмәләре (тиешле пунктларын, өлешләрен, статьяларын күрсәтеп);

закон бозуны раслаган документлар;

ачыкланган бозуларны юкка чыгару буенча чаралар күрү турында таләп һәм (яки) бозуларны китереп чыгарган сәбәпләр һәм шартларны юкка чыгару турында таләпләр, чаралар күрү сроклары;

танытманы үтәү турында Министрлыкка мәгълүмат җиткерү срогы.

5.3. Күрсәтмә төшенчәсе күрсәтмәдә күрсәтелгән срокта үтәлергә тиешле Россия Федерациясе бюджет законын, бюджетка кагылышлы хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салучы башка норматив-хокукый актларны, Татарстан Республикасы бюджетыннан средстволар бирү турында килешүләр (шартнамәләр), дәүләт контрактлары шартларын, дәүләт гарантияләре белән тәэмин ителгән кредитлар һәм займнар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын, Татарстан Республикасы бюджет средстволарын контрольлек объектларының кыйммәтле кәгазьләренә урнаштыру максатларын, тәртибен һәм шартларын бозуны юкка чыгару турында таләптән һәм (яки) Татарстан Республикасы бюджетына китерелгән зыянны каплау турында таләптән торган документны аңлата.

Министрлык күрсәтмәсендә булырга тиеш:

контрольлек чарасы турында төп мәгълүматлар (аны үткәрүгә нигез,

контрольлек чарасы атамасы, контрольлек объекты атамасы, шулай ук контрольлек чарасын үткәрү сроклары);

контрольлек чарасын үткәрү барышында ачыкланган закон бозулар,

закон бозулар суммасы (булганда). закон бозу датасы (чоры);

санга сугылмаган норматив-хокукый актлар нигезләмәләре (тиешле пунктларын, өлешләрен, статьяларын күрсәтеп);

закон бозуны раслаган документлар;

ачыкланган бозуларны юкка чыгару буенча чаралар күрү турында таләп һәм (яки) бозулар китереп чыгарган зыянны каплау турында таләп һәм зыянны юкка чыгару һәм (яки) каплау сроклары;

күрсәтмәне үтәү турында Министрлыкка мәгълүмат җиткерү срогы.

5.4. Танытмаларга һәм күрсәтмәләргә Министр яки аның кушуы буенча Министрның беренче урынбасары, Министр урынбасарлары кул куя.

5.5. Контрольлек чарасы нәтиҗәләре буенча җибәрелгән танытмалар һәм (яки) күрсәтмәләр танытмада һәм (яки) күрсәтмәдә күрсәтелгән срокта контрольлек объектының вазыйфаи затлары тарафыннан мәҗбүри төстә үтәлергә тиеш.

5.6. Контрольлек объекты танытма һәм (яки) күрсәтмәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча билгеләнгән срокта Министрлыкка ачыкланган бозуларны юкка чыгару турында мәгълүмат җибәрә.

5.7. Министрлыкның танытмаларын һәм күрсәтмәләрен юкка чыгару һәм аларга шикаять белдерү суд рәтибендә хәл ителә.

5.8. Бирелгән танытманы һәм (яки) күрсәтмәне үтәмәү мондый танытманы һәм (яки) күрсәтмәне үтәмәгән затка карата гамәлдәге законнар нигезендә җаваплылык чараларын күрүгә китерә.

5.9. Министрлык тарафыннан башка дәүләт органы (вазыйфаи зат) компетенциясенә керүче закон бозу билгеләренә күрсәткән хәлләр һәм фактлар ачыкланганда, мондый хәлләр һәм фактлар турында мәгълүматлар һәм (яки) мондый фактларны расланган документлар һәм башка материаллар тиешле дәүләт органнарына карап тикшерүгә җибәрелә.

5.10. Контрольлек чараларын үткәрү барышында тикшерү Министрлык компетенциясенә кергән административ хокук бозу очрагына күрсәтүче җитәрлек

мәгълүматлар ачыкланганда, административ хокук бозулар турында беркетмәләр тутыруга вәкаләтле Министрлыкның вазыйфаи затлары, Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә, административ хокук бозу турында эш кузгата.

## 6. Үткәрелгән контрольлек чаралары нәтиҗәләрен тормышка ашыруны контрольдә тоту

6.1. Үткәрелгән контрольлек чаралары нәтиҗәләрен тормышка ашыруны контрольдә тотуның максаты булып Министрлык тарафыннан контрольлек объектына җибәрелгән документларда бәян ителгән таләпләрне тулысынча, сыйфатлы һәм үз вакытында үтәү тора.

6.2. Министрлык танытмаларын һәм (яки) күрсәтмәләрен үтәүне контрольдә тоту түбәндәгеләрне үз эченә ала:

танытмалардагы һәм (яки) күрсәтмәләрдәге таләпләрне үтәүнең, Россия Федерациясе законын һәм башка норматив-хокукый актларны бозуларны юкка чыгару буенча планлаштырылган чараларны үтәүнең тулылыгын, шулай ук мондый бозуларның сәбәпләрен һәм шартларын анализлау һәм бәяләү:

танытмалар һәм (яки) күрсәтмәләрне үтәмәү, аларны үтәү срокларын бозу очракларында чаралар күрү.

6.3. Танытмалар һәм (яки) күрсәтмәләрне үтәүне анализлау барышында контрольлек объектыннан алардагы таләпләрне үтәүнең барышы һәм нәтиҗәләре турында кирәкле мәгълүматлар, документлар һәм материаллар өстәмә рәвештә соратып алынырга мөмкин.

6.4. Барлык таләпләр үтәлгәндә, танытма һәм (яки) күрсәтмә контрольлектән алына.